**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында КАРАР**

«26» ноябрь 2025 ел № 9

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 26 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 632 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 461 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 461 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы территориясендә яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол

калган хатыннарыннан тыш, 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту җайланмасы;
- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотумәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлегенең Егоркино авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлегенең Егоркино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2025 елның 28 октябрендәге 1 номерлы карарны үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Егоркино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: А.И.Борисов

Егоркино авыл җирлеге башлыгы А.И.Борисов